ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 28

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«21» 01 2019 г.

2018 ел өчен коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелегенең һәм лицензия контроленең нәтиҗәләре турында хисап раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2018 ел өчен коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелегенең һәм лицензия контроленең нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.
2. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары С.В.Заһидуллинга йөкләргә.

Башлык С.А.Крайнов